## 2020-2021 нче уку елына анализ.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе "Җөри балалар бакчасы" 1 катлы бинада, 9 сәгатьле (7.00-16.00) 5 көнлек режимда эшли. Бакчада 1катнаш төркем, 20 урынга исәпләнгән. Педагоглар коллективында барлыгы 1 педагог эшли

### Белем дәрәҗәсе

| Барлыгы | Урта –һөнәри белем |
|---|---|
| 1 | 1- % |
| | Тәрбияче – Михайлова А.П. |

### Категория дәрәҗәсе

| Барлыгы | Беренче категория |
|---|---|
| 1 | 1 педагог - |
| | Михайлова А.П. |

### Эш стажы

| Категория | | |
|---|---|---|
| | | 20-25 |
| Бакча мөдире | | Абузарова Р.М. |
| тәрбиячеләр | | Михайлова А.П. |

### Яшь

| | 40-49 |
|---|---|
| Тәрбияче | Михайлова А.П. |

Педагогик коллектив үзбелемнәрен район методик берләшмә утырышларында,консультацияләрдә, ачык шөгыльләрдә һәм мероприятиелар, семинар- практикумнарда, педагогик киңәшмәләрдә күтәрәләр. Уку елы барышында методик кабинет тәрбиячеләр ясаган брошюралар,уеннар, отчетлар белән тулыланды.

Нәтиҗә: коллектив оешкан, бердәм эшли, педагогларда мәктәпкәчә яшьтәге балаларга тәрбия һәм белем методикасы көчле. Шәхси һәм профессиональ сыйфатлары әйбәт, тормышта һәм эштә үзләрен үрнәк яктан гына күрсәтәләр, бу үз чиратында коллективта уңай атмосфера тудыра.

Мамадыш муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе "Җөри балалар бакчасы" балалар бакчасында тормышка ашырылучы программалар:

- Төп белем бирү программасы (ООП)
- 2017-2021 нчы елларга Үсеш программасы
- Примерная основная общеобразовательная программа дошкольного образования «От рождения до школы», авторы Н.Е. Веракса, Т.С. Камарова, М.А. Васильевой Москва, 2014 г.

2019-2020 нче уку елында бакчага йөргән балалар программаны тулысынча100% үзләштерде.

Көндәлек режим елның җылы һәм салкын вакыты өчен аерым ясала һәм үтәлә, ул балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен, физик һәм акыл үсеше эшчәнлеген, СанПин нормаларын исәпкә алып программага таянып төзелә.Шөгыльләр барысы да үз вакытында тиешле дәрәҗәдә үткәрелде.

Бакчада сәламәтлекне саклау һәм чыныктыру чаралары өстендә даими эш алып барыла, саф һавада йөрү, саф һавада физультура үткәрү, ата-аналар белән берлектә спорт мероприятиеларында катнашу эше алып барыла. Балаларны ашату 10 көнлек меню аша, сыйфатлы ризыклар әзерләнә.

Төркемдә сәламәтләндерү почмагы эшләнгән, яшь узенчәлекләренә карап тиешле инвентарьлар, кулдан эшләнгән традицион булмаган сәламәтләндерү чаралары куелган.

Балалар һәр чак тәрбияче, кече тәрбияче күзәтүе астында. Бу уку елында җәла-каза, бәхетсезлек очраклары теркәлмәде.Төркемнәргә кабул ителгән яңа балалар адаптация чорын яхшы үттеләр.

**Сәламәтлек төркеме**

| Сәламәтлек төркеме | 2017-2018 нче уку елы | 2018-2019 нче уку елы | 2019-2020 нчы уку елы | 2020-2021 |
|---|---|---|---|---|
| Беренче | | | | |
| Икенче | 11 | 13 | 10 | 8 |
| Өченче | | | | |
| дүртенче | | | | |
| Барлыгы бала саны | 11 | 13 | 10 | 8 |

**Авырту сәбәпле калдырган көннәр**

| яшь | 2017 нчы ел | 2018 нче ел | 2019 нче ел | 2020 |
|---|---|---|---|---|
| 1 -7 | 0 | 0 | 0 | 0 |

**Методик тема:**
**«ФГОС таләпләренә тәңгәл китереп һәм белем бирүнең сыйфатын күтәрүче инновацион технологияләр кулланып белем һәм тәрбия бирүне оптимизацияләү»**

Педагогик коллектив 2020-2021 нче уку елында түбәндәге бурычлар өстендә эшләде:

1. Мәктәпкәчә белем бирүдә ФГОСны тормышка ашыруда белем бирү процессын оештыру һәм планлаштыру.
2. ФГОС шартларында, заманча педагогик һәм информацион технологияләр кулланып, Татарстан Республикасы дәүләт телләренә өйрәтү сыйфатын күтәрү.
3. Мәктәп һәм бакча арасындагы дәвамчанлыкны камилләштерү.
4. Профессиональ конкурсларда катнашу һәм педагогик тәҗрибәләрен трансляцияләүдә педагогларның активлыкларын арттыру.

Уку елы барышында план буенча системалы рәвештә укыту- тәрбия процессының сыйфатын күтәрү өстендә методик эш алып барылды. 5 педагогик киңәшмә уздырылды.

Бакчабызда даими рәвештә балалар һәм эти-әниләр өчен бик матур кичәләр, бәйрәм иртәләре, уздырылып тора. “Белем бәйрәме”, “Сөмбелә”бәйрәме, “Әниләребезне котлап”- әниләр көненә багышланган бәйрәм иртәсе, Яңа ел бәйрәме, “Әниләребез – кадерлеләребез”- 8 нче март иртәсе, “Әтиләребезне котлап”- 23 нче февраль иртәсе, “Муса Җәлил – шигырь бәйрәме”, Г.Тукайның туган көненә багышлап шигырь, инцинировкалар бәйрәме үткәрделәр. Апрель аенда “Туган тел айлыгы уздырылды. Бакчабызда милли тәрбиянең сыйфатын яхшыртуга зур әһәмият бирелә. Әти-әниләр катнашы белән оештырылган уеннар, бәйрәм-кичәләр халкыбызның җыр-биюләрен, шаян такмакларын халык иҗаты әсәрләрен барларга, яңартырга мөмкинлек бирә. “Сөмбелә”, Нәүрүз” кебек халкыбызның милли бәйрәмнәре балаларның күңелләрендә һәрчак матур истәлек булып балкып торырлар. Балалар һәм эти-әниләр арасында рәсем конкурслары, табигый материалларны кулланып эшләгән эшләр конкурсы, этиләр һәм әниләрнең кул эшләренә уздырылган конкурслар бакчабыздагы тормышны тагын да җанландырып җибәрәләр.